Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты

КАРАРЫ

«04» июль 2019 ел № 66

Территорияне межалау проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү һәм планлаштыру структурасы элементларын билгеләү максатларында, «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә 2019 елның 11 июнендәге 4438и номерлы үзгәрешләр кертү буенча Комиссия бәяләмәсе нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Шәхси эшмәкәр Гайнетдинов Илдус Илкам улына үз акчалары хисабына Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Әлмәт шәһәре, 8 Март урамы, з/у 23б адресы, кадастор номеры 16:45:010103:46 булган булган җир кишәрлегенә карата территорияне межанлау проектын әзерләргә тәкъдим итәргә.

2. «Әлмәт муниципаль районы һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм карап тоту тәртибе нигезендә әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Мөхәммәтҗанов А.А. ка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Валеев